***#студентлардөньясы***

# *Көллият сулышы*

***№ 5***

***02/2023***

## 21 НЧЕ ФЕВРАЛЬ

**ХАЛЫКАРА ТУГАН ТЕЛ КӨНЕ**

***Һәр галимнең, һәр шагыйрьнең сүзе***
***Җитсен иде һәрбер күңелгә,***
***Җилләр, сулар тавышы шикелле үк,***
***Үзләренең асыл телендә.***

***Хәсән Туфан***

# ЯҢАЛЫКЛАР



1 нче февральдән 25 нче февральгә кадәр, Татарстанда Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы һәм Халыкара туган тел көненә багышлап, Г.Тукай исемендәге Арча педагогия көллиятендә “Дуслык күпере” фестивале узды. Чара кысаларында төркемнәр арасында төрле бәйгеләр оештырылды. Барлык студентларны җиңүләре белән котлыйбыз!

---

21 нче февральдә Г.Тукай исемендәге Арча педагогия көллиятендә яшь буынга патриотик тәрбия бирү максатыннан Муса Җәлил музей-квартирасы хезмәткәрләре әдәби-музыкаль композиция тәкъдим итте. Чарада Моабит циклыннан шигырьләр, Җәлилнең фронтта язган хатларыннан өзекләр һәм шагыйрьнең васыятьләре укылды. Ә гитара һәм сугыш еллары җырларының тере тавышы сугыш чоры атмосферасына чумарга һәм герой шагыйрьнең фаҗигале язмышын тоярга мөмкинлек бирде.



---




22 нче февральдә Г.Тукай исемендәге Арча педагогия көллиятендә «Салават күпере» журналы редакциясенең «СалаваTik» лар төркеме кунакта булды. Алар «Әлифба» музеенда экскурсиядә булып, үзләренең «Күңелле Әлифба» китапларын бүләк иттеләр. Ә иң зур вакыйга шул: бүген биредә аларның «Күңелле Әлифба» җырының презентациясе үтте. Төркемгә киләчәктә дә уңышлар телибез, эшләре дәвамлы булсын!

# Туган телен кадерләгән халык кадерле булыр...

21 нче февральдә дөньякүләм туган тел көне билгеләп үтелә. Әлеге халыкара бәйрәм дөньядагы телләрне саклау, аларны киләчәк буынга исән-имин җиткерү макстатыннан оеша.

Татар теле – татарларның милли теле, Татарстанның дәүләт теле, таралышы буенча Рәсәйдә икенче тел. Ул – ЮНЕСКО тарафыннан бөтендөнья халыкара аралашу теле дип саналган 14 телнең берсе. Бу – туган телебез белән горурланырлык мөһим фактор. Татар телендә 7 миллионга якын кеше сөйләшә. Аны белсәң, утызлап телдә аралаша аласың.

Татарларның иң күбе Татарстанда яши. Калган өлеше Россия Федерациясе һәм БДБ илләрендә. Татар теле Үзбәкстан, Казакъстан, Азәрбайҗан, Кыргызстан, Таҗикстан һәм Төрекмәнстанда таралган. Бу телдә сөйләшүчеләр шулай ук Финляндиядә, Америкада, Төркиядә, Кытайда, Япониядә, Австралиядә, Швециядә һәм башка илләрдә дә бар.

Ә хәзер дөньядагы телләр буенча кызыклы фактларга тукталып үтик:

-Дөньяда 6809 тере тел исәпләнә. Аларның 90 процентын 100 меңгә якын кеше куллана.

-50 кеше генә сөйләшә торган 357 тел бар. 46 телне бары тик бер кеше генә саклый.

-Иң авыр телләрнең берсе – кытай теле, иң җиңеле – гавай теле санала.

-Дөньяда 65 төрле алфавит бар. Иң беренче борынгы алфавит үрнәге Сириядәге Унгарит (хәзерге Рас-Шарта) шәһәрендә табылган. Аның барлыкка килү вакыты безнең эрага кадәр 1450 ел тирәсе дип исәпләнә.

-Иң күп хәрефле (72) алфавит Камбоджадагы кхмер телендә генә бар. Иң аз, 11 хәрефе булган алфавит Бутенвиль утравында яшәүче ротокас кабиләсендә.

-Телләрнең иң күп саны Папуа-Яңа Гвинеяда теркәлгән. Биредә дөньядагы барлык телләрнең 10 проценты, башкача әйткәндә, 500гә якыны шунда тупланган.

-Иң катлаулы тел булып Дагестандагы табасаран теле санала. Анда килешләр саны гына да 48гә җитә.

-«а» авазыннан башка бер тел дә юк. Иң борынгысы «о» авазы икән. Ул безнең эрага кадәр 1300 нче ел тирәсендә финикиялеләр алфавитына кертелгән һәм бер дә үзгәрмичә бүгенге көндә дә кулланыла.

**Шиһабеддинова Г.Х.**

# *Мәхәббәтсез дөнья ямьсез*

**Кешенең матурлыгы - мәхәббәтендә. Мәхәббәт ул - эчтән яктыртып торучы нур. Мәхәббәте белән бергә кабына да бергә сүнә кеше. Тәмам бүтәнгә әверелә, караңгылана - танымый башлыйсың...**

**Шәүкәт Галиев**


**Мәхәббәт кешене матур итә.**

**Гадел Кутуй**


**Без сөяр өчен туганбыз,**
**Без янар өчен туган.**
**Без барабыз бәхетебезгә**
**Мәхәббәт сызган юлдан.**

**Фәнис Яруллин**

**Мәхәббәт**
**Ул үзе иске нәрсә,**
**Ләкин**
**Һәрбер йөрәк аны яңарта,**
**Тиле яшьлек ярты гомрен бирә**
**Аның хисе белән янарга...**



**Һ. Такташ**



# Гомерем минем моңлы бер җыр иде...

15 нче февральдә татар шагыйре, Советлар Союзы Герое Муса Җәлилнең тууына 117 ел тулу билгеләп үтелде. Язучы авыр һәм кыска гомер кичерсә дә, авыр мизгелләрдә дә иҗатка һәм шигырьләр язуга көч тапкан. Истәлекле көнне Муса Җәлилнең катлаулы язмышы һәм аның нацистлар әсирлегендә язылган шигырьләрен искә төшердек.

Муса Җәлил – татарның бөек улы, күренекле шагыйрь, яугир, батыр. Шагыйрьнең иҗаты бүгенге көндә дә күп әдәбиятчылар, тарихчылар, телчеләр тарафыннан өйрәнелә. Без дә, Арча педагогия көллиятенең гимназия сыйныфы укучылары, ел саен 15 нче февральдә Муса Җәлилне искә алабыз. Укучылар өчен “Гомерем минем моңлы бер җыр иде...” дип исемләнгән шигырь сөйләүчеләр конкурсы үткәрелү – моның ачык мисалы. Әлеге бәйгедә 24 укучы катнашты. Бигрәк тә шагыйрьнең “Моабит дәфтәрләре”ндә тупланган шигырьләрен сөйләүчеләр күп булды.

Бәйгедә 3 нче урынны Галиахмәтова Сөмбел, Вәлиева Язилә яулады. 2 нче урынны Шәмсетдинов Морат белән Сәйфетдинова Рисәлә бүлеште. 1 нче урынга Фазлиева Зәмирәгә лаек булды. Укучыларга дипломнар тапшырылды.

Моннан тыш, 232 нче төркем студентлары, укучылар өчен, Муса Җәлилгә багышланган сыйныфтан тыш чаралар да үткәрде. Укучыларга Муса Җәлилнең, аның көрәштәшләре турында тулы мәгълүмат бирелде. Муса Җәлилнең күп кенә шигырьләре көйгә салынган. Студентлар Муса Җәлилнең сүзләренә язылган җырлар да башкарып киттеләр. Чара бер сулышта узды. Студентлар тарафыннан әзерләнгән күргәзмә дә укучыларның игътибарын җәлеп итте.

**Фазлиева Зәмирә, 7 нче сыйныф укучысы**

## Муса Җәлил турында 10 кызыклы факт

1. Шагыйрь тумышы белән Татарстаннан түгел, аның туган ягы – Оренбург өлкәсенең Мостафа авылы;
2. Әтисенең исеме авыл исеме белән тәңгәл – Мостафа, әнисенеке – Рәхимә;
3. Беренче шигырен 9-10 яшендә яза;
4. Матур җырлый һәм рәсем ясый торган була;
5. Пушкин, Некрасов, Шевченко, Тихонов, Маяковский, Барто, Маршак кебек шагыйрьләрнең әсәрләрен татарчага тәрҗемә итә;
6. Муса Җәлил "Ялкын" журналына нигез салучы булып тора;
7. Фронтка үзе теләп китә;
8. Шагыйрь тоткынлыкта 791 көн була;
9. Муса Җәлил Ватанына хыянәт итүдә гаепләнә, тоткынлыкта чакта язган шигырьләре тупланган Моабит дәфтәрләре туган ягына әйләнеп кайткач кына аның исеме әлеге "сатлыкҗан" дигән кара тамгадан алына. Ул гына да түгел, шагыйрьгә Советлар Союзы Герое исеме бирелә;
10. Казанда М. Җәлил музее, урамы бар, шулай ук опера-балет театры да аның исеме белән аталган.

**Гыйләҗева А.Ф.**






# ВАТАН АЛДЫНДА МИНЕМ БУРЫЧЫМ

*Минем уйлавымча, һәр кеше үз вакытында, бу дөньяда яшәгәндә, Ватаныбызны сакларга тиеш. Бу – безнең изге бурычыбыз.*

***Галәветдинов Илназ, 341 нче төркем студенты***

*Ватан – ул синең туган җирең генә түгел, ә шунда яшәгән кешеләр дә. Аңлыйм, кешеләр төрле була. Әмма иң мөһиме: яхшылык эшләргә теләк булу. Үзең өчен генә түгел, барлык кешеләр өчен дә. Бөтен кеше дә шулай уйларга тиеш дип уйлыйм.*

***Гайфуллин Муса, 341 нче төркем студенты***

*Без Ватан, Туган ил алдында бурычыбызны һәрвакыт истә тотарга тиеш. Ватаныбызга авыр чакта, хәлне яхшырту өчен кулдан килгәннең барысын да эшләргә кирәк.*

***Харрасов Азат, 341 нче төркем студенты***

*Ватан – ул һәркем өчен горурлык, бердәмлек. Илебез алдында бурычыбызны үтәргә тиешбез.Чөнки без шушы матур, тыныч илебездә яшәгәндә, безнең бабайларыбызга, әтиләребезгә бурычлы. Алар безне тыныч яшәсен дип, үзләренең гомерләрен биргәннәр. Минем өчен дә Ватаныбыз каршында изге бурычыбызны үтәү бик мөһим.*

***Нуриев Айрат, 341 нче төркем студенты***

*Икенче елга безне дә, Алла боерса, армия сафларына алалар. Минем әтием дә ике ел хезмәт итеп кайткан. Аннан үрнәк алып, мин дә барырга булдым. Туганнан туган абыем да бүгенге көндә Украина җирләрендә. Без аның хәлләрен белешеп торабыз. Тиздән исән-сау җиңү белән әйләнеп кайтырлар дип көтеп торабыз.*

***Гыйбадуллин Рәмис, 341 нче төркем студенты***

*Минемчә, Ватан – туган авыл, туган гаилә, туган ил ул. Без туган җиребездә генә җан тынычлыгы, тормышның матурлыгын, гүзәллеген табабыз. Әйе, бүген без – шаян, шук студентлар. Шулай да Ватаныбызны саклаган һәм тормышыбызны тыныч тоткан ир-егетләребезгә рәхмәт әйтәсе килә.*

***Кәримуллин Инсаф, 341 нче төркем студенты***

*Без матур һәм якты тормышта яшибез. Хәзерге вакытта төп бурычыбыз – уку, әти-әни йөзенә кызыллык китермәү... Мин армиядә хезмәт итүне изге бурычым дип уйлыйм.*

***Шәйхиев Ильмир, 341 нче төркем студенты***

*Без дә Ватаныбызны күз карасыдай сакларга тиеш. Бу – безнең бурычыбыз! Ватансыз кеше – ятим кеше. Шуңа күрә телебезне, илебезне, милләтебезне саклау безнең өстә!*

***Галиев Илназ, 341 нче төркем студенты***



**Редколлегия:**

Шиһабеддинова Г.Х.

Гыйләҗева А.Ф., Фазлиева З., 341 нче төркем студентлары